Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль район Советы

**КАРАР № XV-3**

2021 елның 1 декабре

Балык Бистәсе штп.

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районында биләүләре коррупция куркынычы белән бәйле булган муниципаль хезмәт вазыйфалары исемлеген раслау турында

“Коррупциягә каршы тору турында” 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Президентының “Коррупциягә каршы тору турында” Федераль законның аерым нигезләмәләрен тормышка ашыру чаралары хакында” 2010 елның 21 июлендәге 925 номерлы Указы, муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы Кодексы, Татарстан Республикасы Президентының “Коррупциягә каршы тору турында” Федераль законның аерым нигезләмәләрен гамәлгә ашыру чаралары хакында” 2010 елның 30 сентябрендәге ПУ-636 номерлы Указы нигезендә, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Советының 2016 елның 23 апрелендә кабул ителгән “Балык Бистәсе муниципаль районы” муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүгә дәгъва итүче гражданнар тарафыннан керемнәр, мөлкәт һәм мөлкәт сыйфатындагы йөкләмәләре турында, шулай ук “Балык Бистәсе муниципаль районы” муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәт сыйфатындагы йөкләмәләре турында мәгълүмат бирү хакында” гы X-4 номерлы карарын игътибарга алып,Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советы КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районында кушымтада бирелә торган биләүләре коррупция куркынычы белән бәйле булган муниципаль хезмәт вазыйфалары исемлеген расларга (алга таба – Исемлек).

2. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы җирле үзидарә органнарының кадрлар хезмәтләренең коррупциячел һәм башка хокук бозуларны профилактикалау эше өчен җаваплы вазыйфаи затларына:

Исемлеккә кертелгән вазыйфаларны биләүче муниципаль хезмәткәрләргә эштән киткәндә “Коррупциягә каршы тору турында” 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законның 12 маддәсендә каралган чикләүләрне, бурычларны һәм җаваплылыкны аңлатырга;

әлеге карарны Исемлеккә кертелгән муниципаль хезмәткәрләр игътибарына җиткерергә.

3. Балык Бистәсе муниципаль районы Советының “Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районында биләүләре коррупция куркынычы белән бәйле булган муниципаль хезмәт вазыйфалары исемлеген раслау турында” 2017 елның 24 июлендәге XX-5номерлы карарын үз көчен югалткан дип танырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”нда урнаштырырга.

5. Карарның үтәлешенә контрольлек итүне законлылык, хокук тәртибе, муниципаль милек һәм җирле үзидарә буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль район
Башлыгы

И.Р. Таҗетдинов

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль
район Советының 2021 елның
1 декабрендәге XV-3 номерлы
карары белән расланды

## Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районында биләүләре коррупция куркынычы белән бәйле булган муниципаль хезмәт вазыйфалары исемлеге

### 1. Балык Бистәсе муниципаль районы Советы аппаратында муниципаль хезмәт вазыйфалары

1.1. Муниципаль хезмәтнең югары вазыйфасы:
Совет аппараты җитәкчесе.
1.2. Муниципаль хезмәтнең төп вазыйфасы:
мөстәкыйль бүлек башлыгы.
1.3. Муниципаль хезмәтнең әйдәп баручы вазыйфалары:
мөстәкыйль бүлек башлыгы урынбасары;
муниципаль район Башлыгы ярдәмчесе.

### 2. Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетында муниципаль хезмәт вазыйфалары

2.1. Муниципаль хезмәтнең югары вазыйфалары:
Башкарма комитет җитәкчесе;
Башкарма комитет җитәкчесе урынбасары.
2.2. Муниципаль хезмәтнең төп вазыйфалары:
мөстәкыйль бүлек башлыгы;
Башкарма комитет органы башлыгы.
2.3. Муниципаль хезмәтнең әйдәп баручы вазыйфалары:
мөстәкыйль бүлек башлыгы урынбасары;
Башкарма комитет органы башлыгы урынбасары.
2.4. Муниципаль хезмәтнең өлкән вазыйфалары:
бүлекнең, Башкарма комитет органының баш белгече;
бүлекнең, секторның, Башкарма комитет органының әйдәүче белгече.

### 3. Җирле үзидарәнең башка органында, башка җирле үзидарә органы аппаратында муниципаль хезмәт вазыйфалары

3.1. Муниципаль хезмәтнең югары вазыйфалары:
җирле үзидарәнең башка органы җитәкчесе;
җирле үзидарәнең башка органы җитәкчесе урынбасары.
3.2. Муниципаль хезмәтнең төп вазыйфасы:
мөстәкыйль бүлек башлыгы;

3.3. Муниципаль хезмәтнең әйдәп баручы вазыйфасы
мөстәкыйль бүлек башлыгы урынбасары.

3.4. Муниципаль хезмәтнең өлкән вазыйфасы
бүлекнең баш белгече.